| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кадыбашского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадыбаш авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2025 Кадыбаш авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кадыбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Кадыбаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кадыбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2025 елның 23 ноябрь көнне 12 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кадыбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2025 елның 23 ноябрь көнне 12 сәгать 30 минутта билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүлүне гамәлгә ашырырга:

-1 нче этап: Кадыбаш авылының Гали ур., Касай ур., Клуб ур., Яшьләр ур. яшәүчеләр.

-2 нче этап: Кадыбаш авылының Тауасты ур., Совет ур. яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, кулланууга ризамы?

4.1 Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4.2. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; халыкка су бирү (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу; җирлекне су белән тәэмин итү (тирән насосларны сатып алу һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрен ремонтлау, су колонкаларын ремонтлау) һәм су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар.

4.3 Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу һәм янгын сүндерү автомобилен карап тоту) янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү һәм башка чыгымнар;

4.4 Кадыбаш авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту чокырларга ремонт (Тау асты, Яшьләр, Гали урамы юлларына вак таш, ком сатып алу һәм салу, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

4.5. Торак пункт территориясен ( үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү: Кадыбаш авылында дизель ягулыгы, дизель мае, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу; тракторчыга

хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар).».

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадыбаш авылы, Клуб ур., 49 а йорты, авыл мәдәният йорты.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Х.Л.Закиров

Совет Кадыбашского сельского поселения
Кадыбаш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601005572